СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 09 » сентябрь 2020 ел** **№ 347**

**Арча район Советының 2015 елның 26 октябрендәге 12 номерлы "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында" карары белән расланган Татарстан "Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә" гә үзгәрешләр кертү хакында" (2016 елның 10 ноябрендәге 76 номерлы, 2017 елның 24 мартындагы 112 номерлы, 2017 елның 18 июлендәге 133 номерлы, 2019 елның 14 мартындагы 238**

"Мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында" Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2020 елның 8 июнендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1. Арча район Советының 2015 елның 26 октябрендәге 12 номерлы "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында" карары белән расланган Татарстан "Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә" гә (2016 елның 10 ноябрендәге 76 номерлы, 2017 елның 24 мартындагы 112 номерлы, 2017 елның 18 июлендәге 133 номерлы, 2019 елның 14 мартындагы 238 номерлы, 2020 елның 11 мартындагы 313 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1) 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"10. Вакантлы вазыйфаны биләп торуга конкурс үткәрү турында хәбәрдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) вакантлы вазыйфаның тулы исеме;

2) әлеге вазыйфаны биләп торуга дәгъвачыга карата куелган таләпләрне үз

эченә алган конкурсны үткәрү шартлары;

3) әлеге Нигезләмәнең 10 пункты нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты һәм кабул итү срогы;

4) конкурсны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында белешмәләр;

5) конкурс турында тулырак мәгълүматны бастырып чыгару чыганагы турында белешмәләр (телефон, факс, электрон почта, электрон адрес);

6) хезмәт килешүе проекты.

**2) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"12. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы конкурс комиссиясенә түбәндәге документларны тапшыра:

1) конкурс комиссиясе рәисе исеменә язылган шәхси гариза;

2) әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, тәрҗемәи хәл (автобиография);

3) паспорт яисә аны алмаштыручы документ күчермәсе;

4) тиешле һөнәри белем, эш стажы һәм квалификацияне раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүмат (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66_1 статьясы), хезмәт килешүе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

һөнәри белем турында документлар күчермәләре, шулай ук гражданин теләге буенча - хезмәт итү урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәтләре тарафыннан расланган өстәмә һөнәри белем бирү турында, гыйльми дәрәҗә бирү турында, гыйльми исем бирү турында);

5) җирле үзидарә органнарының муниципаль норматив хокукый актларында билгеләнгән форма буенча - граждан муниципаль хезмәткәрләр әлеге белешмәләрне тапшырырга тиешле муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегенә кергән муниципаль хезмәт вазыйфаларына кергәндә, муниципаль хезмәткә керү елына кадәрге ел өчен керемнәр турында белешмәләр, шулай ук муниципаль хезмәткә керү елына кадәрге ел өчен хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр; .

6) гражданның муниципаль хезмәткә керүгә яисә аны башкаруга комачаулаучы авыруларның булмавы турында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен билгеләнгән форма буенча медицина оешмасы бәяләмәсе;

7) физик затны Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык;

8) хәрби исәпкә алу документлары - запаста торучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

9) шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;

10) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_1 статьясында каралган белешмәләр;

11) федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы,
Арча район Советы рәисе И.Г. Нуриев